ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Әдәмсә авыл җирлегенең Бакташ авылында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

2025 елның 24 октябрьдан № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Әдәмсә авыл җирлегенең Яңа Бакташ авылында гражданнар җыены нигезендә

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Әдәмсә авыл җирлегенең Бакташ авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, Россия Федерациясе Кораллы көчләренең контракт буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләреннән, мобилизацияләнгәннәрдән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, 90 яшьтән өлкәнрәк затлардан тыш, 2026 елда 600 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү (материаллар сатып алу, мәйданчык урнаштыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү);

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (кышкы чорда юлларны кардан чистарту, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү).

3. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: httrs://pravo.tatarstan.ru, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә: https://novosheshminsk.tatarstan.ru, гражданнар җыены нәтиҗәләрен кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Бакташ авылында, Кояш урамында, 7 нче йорт янында мәгълүмат стендына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әдәмсә авыл җирлеге башлыгы
Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районының А.И. Нәҗметдинова